
## Туган ягыбызда кышлаучы кошлар

**/Күңелле тәнафес/**



1 - Гәүдәсенең озынлыгы 13–16 см, авырлыгы 19–25 г. Каурый капламы куе, йомшак, аркасы зәңгәрсу, бүксәсе ак, ян-яклары ачык җирән, канатлары һәм койрыгы коңгырт төстә. Күзе турысыннан башы буйлап кара буй уза. Томшыгы озын, конуссыман, көчле. Койрыгы кыска, туры. Аяклары кыска, көчле.

2 - Чебенче кошлар семьялыгына караган сайрар кош.

3 - Каргалар ыругыннан булган кош төре.

4 - Күгәрченнәр гаиләсеннән булган кош. Аның ватаны булып Европа, Көньяк-көнбатыш Азия һәм Төньяк Африка санала.

5 - Кыргавыл кошлар семьялыгының тавыксыманнар отрядыннан.

6 - Башы зур, 270 градуска борыла ала. Күзләре зур, алга карый. Күпереп торган йомшак каурый капламы тавышсыз гына очарга мөмкинлек бирә. Бик яхшы ишетүчән. Тире җыерчыкларыннан, каты каурыйлардан торучы тышкы колак яфраклары һәм каты каурыйлары бит дискы ярдәмендә тавыш чыганагының урынын төгәл билгелиләр. Томшыгы ыргаксыман, төбендә каты тире капламы бар.

7 - Сайрар чыпчыклар семьялыгыннан. Күпчелегенең түбәсе кара, кайберсе бүрекле, ян-якларында ак таплары булган башлы.

8 - Өтергесыман томшыклы, агач буйлап үрмәләргә сәләтле, очарга яратмаучы, әмма кирәк чакта, бик тиз оча ала торган кош.

9 - Тау чыпчыклары семьялыгыннан сайрар кош.

10 - Кыргавыл кошлар семьялыгыннан һәм боҗырлар ыругыннан утрак кош. Аучылык өчен кыйммәтле объект булып исәпләнә.

11 - Карга кошлар семьялыгыннан каргалар ыругының кошы. Гәүдә озынлыгы 34–39 см, авырлыгы 175–280 г.

12 - Каргалар семьялыгындагы кош. Агач һәм куаклар үскән биотопларда яши. Шәһәр һәм авылларда оялый.

13 - Дөнья фаунасында 18 төре билгеле, Европада, Азия һәм Африкада таралганнар. Кайбер төрләре Америка, Австралия һәм Яңа Зеландиядә яши.

14 - Урта зурлыктагы, кәкре томшыклы һәм озын тырнаклы ерткыч кош.

*Кроссвордны редколлегия әгъзалары төзеде*

**/Безнең спорт/**



12 ноябрь көнне Әлки районы үзәге булган Базарлы Матакта Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы депутаты Хайруллин Айрат Нәҗип улы истәлегенә багышланган Республикакүләм билбау көрәше уздырылды.

Безнең мәктәпнең VII сыйныф укучылары **Җамалетдинов Зөлфәт** белән **Сәгъдиев Рәмзис** үз авырлыкларында III урыннарны алып каййтылар. Яшь батырларны әлеге уңышлары белән котлыйбыз, алдагы бәйгеләрдә дә зур уңышлар телибез!

**/Чал тарихта эзле без!/**

Бу йөзек сыныгын безнең мәктәп укучылары Чиялек янындагы кырдан 1990 еллар ахырында табып алган иде.



Йөзек кашында нәрсә сурәтләнгән икән? Дөрес җавап бирүчене бүләк көтә.

**/Котлыйбыз!/**



Ноябрь аенда дөньяга килгән дустыбыз **Нурматова Асияне** (VI сыйныф) туган көне белән котлап, ныклы сәламәтлек, укуында зур уңышларга ирешүен телибез.

**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары – Асия Нурматова, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Настя Сафеева.**


# Мәктәп хәбәрчесе

**№9**
**(№70)**
**ноябрь 2025 ел**

***Түбән Майна урта мәктәбе газите***

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


**/ Мөхәррир минбәре/**

### *Олимпиадаларда катнашуның әһәмияте*



Хәзерге заманда белем алу һәркемнең тормышында мөһим урын алып тора. Ә аны практикада куллана белү тагын да зуррак әһәмияткә ия. Уку барышында без балаларны төрле ярышларда, конференцияләрдә, олимпиадаларда катнаштырырга тырышабыз. Йөргән таш кына шомара дигәнне күз алдында тотып, укучыларыбызны зуррак мәйданнарга алып чыгып торабыз. Шушы юлда олимпиадалар – яшь буын өчен үзенчәлекле бер сынау мәйданы. Ә ни өчен соң нәкъ менә олимпиадаларда катнашу укучы өчен әһәмиятле? Бу сорауга җавапны берничә юнәлештә эзләргә мөмкин.

Беренчедән, олимпиадаларда катнашу укучының фәнни белемен тирәнәйтүгә һәм системалаштыруга ярдәм итә. Мәктәп программасы кысаларында алган белемнәр еш кына чикле була. Ә олимпиадаларга әзерләнү процессы фәннең әлеге өлкәсен тагын да ныграк өйрәнүне, төрле чыганаклар белән эшләүне таләп итә. Бу укучыга теманы төрле яктан аңларга, мәсьәләләрне чишүнең яңа ысулларын үзләштерергә мөмкинлек бирә. Нәтиҗәдә, белемнәр системага салына, логик фикерләү сәләте үсә.

Икенчедән, олимпиадалар – сәләтләрне үстерү өчен менә дигән мөмкинлек. Биремнәре гадәти булмаган чишелешләр табарга, иҗади якын килергә мәҗбүр итә. Укучы мәсьәләне анализлый, төрле юллар эзли, нәтиҗә ясый. Бу процесс уйлау сәләтен, креативлыкны һәм проблемаларны чишү осталыгын үстерә. Шулай ук аңа әзерләнү вакытында максатчанлык, тырышлык һәм җаваплылык кебек сыйфатлар да формалаша.

Өченчедән, олимпиадаларда катнашу фәнгә кызыксынуны арттыра һәм яңа белемнәргә омтылыш уята. Уңышлы чыгыш ясау укучыга үз көченә ышаныч бирә, аны тагын да үсәргә һәм камилләшергә этәрә; фикердәшләр белән аралашу, тәҗрибә уртаклашу һәм яңа дуслар табу өчен дә яхшы мәйданчык.

Дүртенчедән, олимпиадаларда катнашу киләчәккә юл ача. Күп кенә югары уку йортлары олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм призерларга өстәмә ташламалар тәкъдим итә. Бу исә яхшы уку йортына керү һәм яхшы карьера башлау өчен менә дигән мөмкинлек.

Олимпиадаларда катнашу тәҗрибәсе фәнни эшчәнлеккә кызыксыну уятырга һәм киләчәктә галим булырга этәрергә мөмкин. Бу шәхси үсеш өчен дә бик мөһим. Укучы үз мөмкинлекләрен сыный, көчле һәм авырсынган якларын ачыклый. Җиңүләргә ирешү һәм җиңелүләрдән сабак алу тормыш тәҗрибәсен баета. Мондый ярышлар шәхеснең үсешенә, аның максатчанлыгын һәм үз-үзенә ышанычын арттыруга ярдәм итә. Укучы һәрвакыт аралашу, яңа дуслар табу нәтиҗәсендә фикере дә ныгый. Ул төрле хәлләрдә дә югалып калмаслык шәхес булып җитешәчәк.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк, ярышларда катнашу – укучы өчен белем алу, сәләтләрне үстерү, киләчәккә юл ачу һәм шәхси үсеш өчен бик әһәмиятле мөмкинлек. Бу – үз көчеңне сынап карау, яңа дуслар табу һәм кызыклы фән дөньясын ачу өчен менә дигән ысул. Һәр укучыны олимпиадаларда катнашып, үзенең сәләтен ачарга һәм үстерергә чакырабыз!

***Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир***

## *Әниләр көне белән!*



***Әниемне бәйрәм белән***
***Котлар идем һәрдаим.***
***Тик әнкәем үзе миңа***
***Бәйрәм ясый көн саен.***

***Иртә торып кояш белән***
***Өстәл көйли елмаеп.***
***Мәктәпкә барырга уята***
***Аркамнан гына сөеп.***

***Хәлләремне сорап тора,***
***Ярдәм итә дәрескә.***
***Сабыр итеп өйрәтә***
***Мине ул һәрбер эшкә.***

***Кояш кебек елмаеп***
***Өебезгә нур сибә.***
***Яратуыннан өлешне***
***һәркемгә тигез бүлә.***

***Кичәшләре көч өсти,***
***Җылы сүзләре- дәва***
***Әниләрне котласын***
***Җир йөзендә һәр бала.***

***Кадерле әниләр! Сезне бәйрәмегез белән котлап, сәламәтлек, озын гомер телибез. Бездән, балаларыгыздан, бары тик шатлыклы хәбәрләр генә ишетсәгез иде. Сезнең безгә биргән җылыгыз, назыгыз, кайгыртуыгыз тормышыбызда терәк, таяныч булыр. Рәхмәт сезгә, әниләр!***

*"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе*

## Узган айның тәрбияви чаралары

6 ноябрь – Халыклар бердәмлеге көне, тирән рухи мәгънәгә ия. Ул безне бердәм булырга, ата-бабаларыбызның каһарманлыгын хөрмәт итәргә өйрәтә. Бу бәйрәмне балалар кечкенәдән белеп үсәргә тиеш. Шул уңайдан укучылар белән халыклар бердәмлегенә багышланган әңгәмә үткәрелде. Безнең Татарстан республикасында төрле милләт халыклары – татарлар, руслар, чуашлар, марилар, башкортлар һ.б. үзара дус яшиләр. Бер-берсе белән хезмәттәшлек итәләр,бергәләп күңел ачалар, матур бәйрәмнәр уздыралар.

---



*8 ноябрь – хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган эчке эшләр органнары хезмәткәрләрен искә алу көне буларак билгеләп үтелә. Югары сыйныф укучылары, тәрбия эшләре буенча киңәшче Гөлфия апа һәм сыйныф җитәкчеләре белән берлектә, «Буыннан буынга, хәтердә» дигән сыйныф сәгате үткәрделәр.*

---



*10 ноябрь көнне безнең мәктәптә башлангыч сыйныф укучыларын "Россия бөркетләре" оешмасына тантаналы рәвештә кабул итү уздырылды. "Яшь бөркетләр" сафына барлыгы өч укучы керде. "Россия бөркетләре" – башлангыч мәктәп укучыларыннан илебезнең актив гражданнарын тәрбияләү буенча масштаблы бөтенроссия проекты. Балалар кагыйдәләр, законнар белән таныштылар, ант иттеләр ,"Россия бөркете" дигән җыр башкардылар. Аларны алда җиде баскыч буенча мавыктыргыч сәяхәт көтә. Без аларга чын күңелдән хыялларына, изге гамәлләренә каршы хәерле юлга чыгарга теләп калабыз.*

---



*"Россия мәктәпләрендә кинодәресләр" проекты кысаларында VI-VIII сыйныф укучылары зур кызыксыну белән "Җиңү варислары" һәм "Канатлар" фильмнарын тамаша кылдылар. Фильмнарны караганнан соң, балалар үзләренең тәэсирләре белән уртаклаштылар.*

---

*20 ноябрьдә "Халыкара Бала хокукларын яклау көне" билгеләп үтелә. Бу дата очраклы рәвештә сайланмаган. Ул көнне 1959 елда Бала хокуклары декларациясе кабул ителә. Документның төп максаты – Балаларга бәхетле балачак тәэмин итү. Бу көнгә багышланган чаралар VI-VII сыйныфларда үткәрелде.*

---



Һәр елның 21 ноябрендә Бөтендөнья юл-транспорт һәлакәтләре корбаннарын искә алу көне билгеләп үтелә. Бу чараның төп максаты түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- җәмәгатьчелек игътибарын юлларда куркынычсызлык проблемаларына юнәлтү;
- юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлем һәм җәрәхәтләнү очракларын кисәтү;
- юл хәрәкәтендә катнашучыларның, шул исәптән мәктәп укучыларының да, юлда үз-үзен тоту культурасын күтәрү.

Юл-транспорт һәлакәте корбаннарын искә алу юл хәрәкәтендә катнашучыларның барысына да зур игътибарлылык һәм саклык таләп итүен искә төшерү өчен кирәк. Һәлакәт корбаннары арасында олылар гына түгел, балалар да булуын күздә тотып, мәктәбебездә ЮИД түгәрәге җитәкчесе Рифкат абый Туктамышев әлеге көнгә багышланган чара уздырды. Чарада юлларның никадәр куркыныч тудырганын, корбаннарның күп булганлыгын күрдек. Юл хаталарны гафу итми! Шуңа күрә бик игътибарлы булсак иде дә, машина йөртү таныклыгын чынлап торып укып алсак иде. Законнар бит хаталар өстендә, корбаннар булганнан соң кабул ителә, шуны беркайчан онытмагыз!

---



30 ноябрь – Россия Федерациясе гербы көне. Бу көнне мәктәптә төрле чаралар узды. Башлангыч сыйныф укучылары өчен "Мозаика" интерактив дәресе оештырылды. Ә югары сыйныф укучылары Дәүләт гербы көненә багышланган викторина сорауларына җавап биреп, белемнәрен ныгыттылар.

***Вакыйгалар тезмәсен редколлегия әгъзалары әзерләде***





## Әниләрне хөрмәтлик

Әниләр көне җиткәч, һәр бала үз әнисен котларга әзерләнәдер. Бу көнне әниләргә булган рәхмәт хисләре аеруча көчәя.Чөнки әниләр безгә гомер биргән, тәрбияләгән, яклаган иң кадерле кешебез. Аларның мәхәббәте чиксез, кайгыртуы олы, сабырлыгы исә искиткеч.

Кечкенәдән үк әнием мине җылы кочакларына алып, моңлы җырлар көйләп, йокларга яткыра иде. Ул безнең беренче киңәшчебез, дустыбыз булды. Әни һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер, ул мине аңлый һәм ничек бар, мине шулай ярата белә.

Әниләр көнендә һәркем үзенең әнисенә игътибар күрсәтергә тырыша. Кемдер чәчәкләр бүләк итә, кемдер тәмле ризыклар пешерә, ә кайберәүләр үз куллары белән ясаган открыткасын тапшыра. Иң мөһиме – бу көнне әнигә булган ихлас мәхәббәтеңне, рәхмәтеңне күрсәтү.

Әниләр көне – гаилә, үзара җылылык һәм мәхәббәт бәйрәме. Бу көнне әниләр белән бергә булырга кирәк. Аларга җылы сүзләр әйтеп, кочаклап хөрмәтебезне белдерик. Алар моңа бик тә лаек. Әниләребезгә исәнлек-саулык, озын гомер телик! Әниләр – безнең тормышыбыздагы иң зур байлык.

***Настя Сафеева, VIII сыйныф укучысы***

## Әнием – минем өчен үрнәк

Мин әнием белән бик горурланам. Аның һәрвакыт үз эшенә җаваплы каравы, укучыларына белем бирүгә омтылуы мине сокландыра. Укытучы булу – ул бик зур хезмәт. Чөнки балаларның киләчәге нәкъ менә аларның кулында. Минем әнием дә шуны яхшы аңлый һәм һәр дәресенә җентекләп әзерләнә, яңа ысуллар куллана, балаларны кызыксындырырлык материаллар эзли.

Мин үзем дә еш кына әнигә ярдәм итәм. Мәсәлән, китаплар сайларга, презентацияләр әзерләргә булышам. Әнием миңа рус теле һәм әдәбиятын тирәнтен өйрәнергә булыша, төрле әсәрләрне анализларга өйрәтә. Аның белән бергә китаплар уку – минем өчен зур бәхет. Чөнки ул әдәби әсәрләрне шундый оста итеп аңлата ки, алар яңа яктан ачыла.

Әниемнең укучылары да аны бик яраталар һәм хөрмәт итәләр. Алар еш кына дәресләрдән соң да аның белән аралашалар, киңәшләрен сорыйлар. Әнием һәрвакыт аларга ярдәм итәргә әзер, беркайчан да баш тартмый. Минемчә, яхшы укытучы нәкъ менә шундый булырга тиеш.

Өйдә әнием миңа һәрвакыт ярдәм итә, киңәшләрен бирә. Мин аның белән үз серләремне уртаклашам, чөнки беләм: ул мине һәрвакыт аңлар. Әнием – минем өчен иң якын кеше, иң яхшы дус. Мин аны бик нык яратам һәм аның белән горурланам.

Әнием өйдәге өлкәннәргә дә игътибарлы. Ике бабама, әбиемә дә ул ярдәм итеп тора. Аларны хөрмәтләп, безне дә олыларга ихтирамлы булырга өнди. Әнием белән әтием безне яраткан кебек, бөтен балага да шундый ярату телим.

***Ләйсән Закирова, VIII сыйныф укучысы***

## Минем тырыш әнием

Әнием чит авылга йөреп эшли. Ул - җирле үзидарәдә хисапчы. Әниемнең тырышлыгына, җитезлегенә хәйран калам. Ул беркайчан да зарланмый, авыр дип әйтми. Барысын да өлгерә, барысына да вакыт таба. Күрше-күлән дә аны хөрмәт итә, ярдәм сорап киләләр. Әнием һәркемгә дә булышырга әзер, беркайчан да баш тартмый.

Әнием – минем өчен иң кадерле кеше. Мин аның белән горурланам, аны бик яратам. Аның кебек тырыш, уңган, мәрхәмәтле булырга тырышам. Әнием миңа һәрвакыт үрнәк булып тора. Аның кулларыннан килмәгән эш юк. Тәмле итеп ашарга пешерә, әтием белән күп итеп мал-туар асрыйлар. Өйне дә гел чиста, пөхтә итеп тота.

Мин дә әнигә булышырга тырышам. Бакчада үлән утыйм, өй җыештырам, малларга ашарга әзерлим. Әниемә авыр булмасын өчен, көчемнән килгәнне эшлим. Без бергә бик тату яшибез, бер-беребезне аңлыйбыз, ярдәм итәбез.

***Камил Төхвәтуллин, VIII сыйныф укучысы***

## Әбием бар минем

Әбиләребез – безнең өчен кадерле затлар. Аларның мәхәббәте чиксез, сабырлыгы искиткеч, ә тормыш тәҗрибәсе – зур хәзинә.

Мин үзем дә әбиемне бик яратам һәм аның белән горурланам. Ул бик миһербанлы кеше, һәрвакыт башкаларга ярдәм итәргә әзер, беркайчан да беркемне дә кайгыда калдырмый. Аның йөрәге игелеккә тулы, һәм ул бу игелекне тирә-юньгә тарата. Мин әбиемнең акыллылыгы белән дә горурланам. Ул күпне белгән, күпне күргән. Аның һәрвакыт дөрес киңәше бар, тормыш мәсьәләләрен чишәргә оста. Аның белән сөйләшү – үзе бер мәктәп.

Әбием шулай ук бик тырыш кеше. Ул беркайчан да тик тормас, һәрвакыт эш белән мәшгуль. Аның куллары алтын, ул нәрсәгә тотынса да, барысы да килеп чыга. Аның пешергән ризыклары бик тәмле. Мин аңа сәламәтлек, озын гомер телим. Әнием һәм әбием арасындагы мөнәсәбәтләр минем өчен үрнәк булып тора. Әбием – минем өчен иң якын кешеләрнең берсе.

***Мәдинә Әхсәнова, VIII сыйныф укучысы***